
# Ислам нуры

«Диндә көчләү юк, ләкин өндәү һәм өйрәту бар»
(Коръән Кәрим. 2-256)

12+

№ 19 (695) 10 октябрь 2019 ел (1440, Сәфәр) Дини-иҗтимагый газета 1995 елдан чыга


## Китап вә уку



Гүзәл китаплар – гаҗәеп әйберләр күренәчәк көзге, аулакта сердәш, ялгызлыкта иптәш, гаҗизлек вакытларда ярдәмче, хәсрәтләрдә шатлык китерүче, фикерләрне нурландыручы, үткән заманнар хәлләрен сөйләп торучы, өметләр, вакыйгаларны хикәят итүче, гакыллы кешеләрнең гакылларын күзләргә күрсәтүче аз хаклы, күп файдалы нәрсәләрдер. Шуның өчен китап алуда саранлык итмәгез, китаплардан аерылмагыз! Файдалы китапларны уку күңелгә шатлык китерер, фикергә азык булыр, зиһенгә куәт бирер. Кайбер кешеләр булыр ки, ”Китабы күп” дип, халык арасында исем чыгарыр өчен генә китап җыеп, үзләре дә файда алмаслар, башкаларга да файда алдырмаслар, хәтта эчләрендә ниләр бар икәнен дә белмәсләр. Болар – йөк ташучылар мисалындадыр. Шуның өчен сез үзегез алачак китапларны үзегез файда алу өчен ихтыяр итегез.

**(Риза ФӘХРЕДДИН. “Әхлак гыйлеме”)**

## Чаллы яңалыклары

Чаллының “Нур-Ихлас” һәм “Әбүзәр” мәчетләрендә өлкәннәр көне уңаеннан мәхәллә картларына бүләкләр тапшырылды. “Нур-Ихлас” мәчетендә бу эшне шәһәребез имам-мөхтәсибе Әлфәс хәзрәт Гайфуллин башкарды. Үзенең тәбрикләү сүзләрендә ул өлкән буынга карата хөрмәтле һәм ихтирамлы мөнәсәбәт турында әйтеп китте. “Әбүзәр” мәчетендә бүләкләрне мәчет имам-хатыйбы Колват хәзрәт тапшырды.

***



2 октябрь көнне мөхтәсибәттә мәчет имам-хатыйбларының чираттагы җыелышы булды. Мәҗлес “Чишмә” мәчете имам-хатыйбы Инсаф хәзрәтнең Коръән укуы белән башланды. Җыелышта “Экстремизмга юк” айлыгына нәтиҗә ясалды, мәчетләрдә башланачак якшәмбе укуларына әзерлек турында фикер алышынды. Шәһәребез имам-мөхтәсибе Әлфәс хәзрәт Гайфуллин җомга вәгазендә халыкка 5 октябрьдә мәчетләрдә укулар башлануын, ә 15 октябрь көнне кичке сәгать җидедә “Ак мәчет” мәдрәсәсендә татар теле курсларының беренче дәресе узачагын җиткерергә кирәклеген әйтте.Мәҗлес барышында шәһәребез казые Рөстәм хәзрәт Шәйхевәлиев мәчет имамнарына үз вазыйфаларын ТР МДН тарафыннан бастырылган “Нигезләмә” китабы нигезендә генә башкарырга кирәклеген искәреп китте. Җыелышның икенче яртысында һәр мәчет өчен Диния нәзарәтеннән кайтартылган, исем кушу, никах һәм женазаларны теркәү кенәгәләре тапшырылды. Мөхтәсибәтнең уку һәм укыту бүлеге җитәкчесе Илдар хәзрәт Зияров мәчетләрдә белем бирүче мөгаллимнәрнең аттестация узган булулары мөһимлеген ассызыклады. Мәҗлес дога кылу белән тәмамланды.

***



“Ак мәчет” мәдрәсәсе шәкертләре Түбән Суык-Су авылында Тукай районы мөхтәсибәте оештырган футбол буенча турнирда катнашты. Биредә “Ак мәчет”, Минзәлә, Биклән, Күзкәй, Теләнче-Тамак, Түбән Суык-Су, Калмаш, Наратлык егетләре көч сынашты. Турнирда җиңүне Түбән Суык-Су авылы егетләре яулады.

**Нияз ГАЗИЗОВ.**

## ТР МДН хәбәр итә



Сәфәр аеның бишенче көнендә, Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин җомга намазын Казанның Зур Клыки бистәсендәге “Сәлах” мәчетендә укытты. Әлеге гыйбадәт йорты быел 4 июль көнне ачылган иде. Камил хәзрәтнең вәгазе гыйлем алуның әһәмиятенә һәм Укытучылар көненә багышланды. “Сәлах” мәчетенә мөфти хәзрәт вәгазен тыңларга йөздән артык кеше җыелды.

***

Өлкәннәр декадасында республика мөхтәсибәтләре һәр елны зур активлык белән катнаша. Бу көннәрдә мөхтәсибәтләрдәге барлык җыелышлар, утырышлар һәм чаралар Өлкәннәр көненә багышланып, тантаналы рәвештә әби-бабайларны котлаудан багышланды. Казан шәһәренең Мәрҗани мәчетендә ТР мөселманнары Диния нәзарәтнең Аксакаллар шурасы башкалабыз мәчетләренә йөрүче мөхтәрәм затларны, сугыш ветераннарын, өлкәннәрне, остазларны җыеп, Коръән ашы уздырды.

Шундый җыелышларның берсе Сабада узды. Махсус бәйрәм җыелышының мөхтәрәм катнашучыларын - өлкән яшьтәге имамнарны Саба районы прокуроры Зөфәр Абитов, Саба районы үзәк хастаханәсе баш табибы Марат Йосыпов һәм Саба районы башкарма комитеты җитәкчесенең урынбасары Марат Кәримов котлады. Алар хәзрәтләргә җәмгыятьтә дини гыйлемне арттыру һәм халыкны әхлакый тәрбияләү өлкәсендәге тырышлыклары өчен олы рәхмәтләрен белдерде.

Яңа Чишмә, Чистай, Алабуга, Әлмәт һәм башка мөхтәсибәтләрдә дә өлкәннәрне күчтәнәчләр белән сыйлап, алар хөрмәтенә аш мәҗлесләре уздырдылар, вәгазь укыдылар, дога кылдылар. Әлмәт мөхтәсибәтенең татар “Нур” мәктәбендә өлкәннәр өчен бәйрәм кичәсен балалар оештырды. Мәктәп укучылары әби-бабайларын чакырып, аларга әзерләгән шигырьләрен сөйләде, догалар укыдылар, үз куллары белән ясалган бүләкләр тапшырдылар.

## ЯҢА КИТАП




“Ислам нуры” дини-эшмәкәрлек үзәгендә әледән-әле яңа китаплар дөнья күреп тора. Эчтәлекле, сыйфатлы, мәгънәле басмалар һәр мөселманның, гомумән, һәркемнең өстәл китабы була ала. “Һәфтияк шәриф” китабының тулыландырылган басмасы - шундыйлардан. Әлеге китапны “Ислам нуры” дини-эшмәкәрлек үзәгеннән, аның кибетеннән алырга мөмкин. Адресы: Чаллы шәһәре, ГЭС бистәсе, Үзәк урамы, 72 нче йорт.

## Язылу башланды

“ДУМ РТ Хаҗ”ның Чаллыдагы вәкиллегендә 2020 елга хаҗга язылу башланды.

- Октябрь ае ахырына кадәр иң түбән бәяләр!
- Еш баручыларга пошлина түләү бетерелде!
- Гомрә хаҗга мөстәкыйль бару мөмкинлеге бар. Виза алу ДУМ РТ Хаҗ” аша (11000 сум)

Белешмә өчен телефоннар: 8 917 933 3705; 8(8552) 56-65-99

# Дүрт сорау

Аллаһ Раббыбыз яшәешне яралтты, шулай ук Ул үлемне дә яралтты. Яшәү һәм үлем ул - кешенең ике халәте. Яшәүдән курыкмаган кеше үлемнән дә куркырга тиеш түгел. Яшәү дә, үлем дә Аллаһның чиксез кодрәтенә дәлил булып тора. Берәү дә үзе теләп, үзе теләгән вакытта яки үзе теләгән урында дөньяга килә алмый, дөньядан үтү дә бездән тормый. Никадәр генә дөньяны яратсак та, барыбер калдырып китәчәкбез. Байның да, ярлының да, көчленең дә, көчсезнең дә, хуҗаның да, хезмәтченең дә үлемнән котылып калу чарасы юк. Тирәннәнрәк уйласаң, ул үлем дә - Аллаһның бәндәгә күп хакыйкатьләрне аңлау һәм тану өчен бирелгән мәрхәмәте. Үлемгә әзерләнү ул – хак мөселман өчен үлемнән соңгы халәткә, ягъни Ахирәт тормышына әзерләнү.

Аллаһ Раббыбыз Коръәндә ( «Мүлек» сүрәсе, 2 нче аять): «Әлләзии халәкаль-мәүтә үәл-хәйәәтә ли-йәбелүүәкүм әййүкүм әхьсәнү гәмәлә», - ягъни: «Ул (Аллаһ) үлемне һәм тереклекне халик кылды, йөкләмәләр йөкләп сезне сынар өчен, кайсыларыгыз яхшырак гамәлле икәнлеген белер өчен», - диде. Әгәр игътибар белән карасак, яшәү үлемнән соң килә. Димәк, яшәү үлем белән тәмамланмый икән. Үлем артында тагын икенче төрле яшәеш бар. Ул без күргән-белгән үлчәмнәрдә түгел, әмма ул бар. Ана карынында да без 4 ай да 10 көн үле хәлдә идек, аның соңында Аллаһ әлмисакта яралтылган җаннарыбызны безгә иңдерде. Шул тән дигән савытта күпмедер яшәгәч, җаныбыз үзен дөнья белән бергә яралткан Аллаһ хозурына күчәчәк. Әмма инде җиргә килеп, тән белән бергә яшәгәннән соң җанның халәте, мәңгелек рәхәттә яки михнәттә булуы җирдә яшәгән кыска гына гомере белән бәйләнгән. Бу дөньяда ни чәчсәң, тегә дөньяда шуны урасың, шуның нәтиҗәләрен дә күрәсең.

Үлем ул - мәңгелек халәткә күчү капкасы гына. Аллаһ кушканнарын үтәп, тыйганнарыннан тыелып, нәфесеңнән өстен булып яшәгәнсең икән, үлем ул - мәңгелек сәгадәткә күчү капкасы һәм хак мөэмин аннан курыкмас, җанын җиңел бирер. Әгәр үзеңне генә яратып, Аллаһны танымыйча, нәфес колы булып яшәсәң, үлем - мәңгелек газапка алып керүче капка, андый кеше үлемнән курка һәм җанын да авыр бирә.

Үлемгә әзерләнү ул - үлемнән соң яшәүгә әзерләнү. Һәрвакыт һәм һәр җирдә үзеңнең фәкать Аллаһ колы гына икәнеңне һәм бер Аллаһка гына хезмәт итәргә тиешлегеңне аңлап, Аңа гына гыйбадәт кылып яшәргә тиешсең. Хакыйкый мөэмин бу дөнья өчен генә түгел, мәңгелек бәхете өчен дә тырыша. Бу очракта аңа бу дөньяда да, Ахирәттә дә куркыныч түгел.

Һәркем Аллаһ зиннәтләгән акылын эшкә җигеп, фикерләп карасын, әзерләнәме ул мәңгелектә яшәргә һәм ничек әзерләнә? Әле бирeләчәк сорауларга һәркем җавап әйтеп карасын һәм үзенең әзерлегенә бәя бирер...

Беренче сорау. Кем синең яралтучың һәм хуҗаң, ягъни Раббың кем? Һәркайсыбыз: «Раббым – бөтен галәмнәрнең хуҗасы Аллаһ», - дип әйтә. Әлхәмдүлилләәәһ, Аллаһны танымаучылар күп түгел. Каршы сорау: «Һәрвакыт Раббыбыз Аллаһ искә алмый исеңдәме, Аның кануннары буенча яшисеңме? Ягъни ышануың-тануың телең белән генәме, әллә гамәлең белән дәме?» Яшәвеңнең һәр мизгелендә Аллаһ исеңнән чыкмаса, һәр эшеңне Ул кушканча һәм Ул риза булырлык итеп яшәсәң - борчылма. Кайвакытта исеңнән чыгып китә икән, тынычлана алмыйсың. Авырлык килгәндә генә исеңә аласың икән, башка вакытта нәфесең артыннан, байлык артыннан чабасың, башкаларга охшар өчен, үз рәхәтлегең өчен яшисең икән, бел, ул вакытларда синең Раббың - йә нәфсең, йә байлык, йә кешеләр, йә шайтан. Аллаһ мул уңыш бирә, аның безгә кушкан хөкеме дә бар: уннан бере синеке түгел, ятимнәр, мескеннәр, мохтаҗлар өлеше. Әле син ул өлешне тиешле урынга тапшырдыңмы? Юк икән, димәк, Раббыбызны истә тотмыйсың, байлыкка өстенлек бирәсең. Намаз вакыты кереп, намаз укымасаң, ураза җитеп, ураза тотмасаң, ул вакытта кемгә буйсынасың? Кем сине ышандыра ала шулвакыт әҗәл килмәс, дип. Әгәр шул килеш үлеп китсәң, димәк, Раббым, дип йә нәфсеңне, йә байлыкны, йә шайтанны, йә кешеләрне санап, дөньядан көферлек белән үтеп киттең, дигән сүз, Аллаһ сакласын. Кешеләр, бәлки, сине ышанучы дип санарлар, әмма бу очракта син Аллаһка ышанып үлмәдең. «Раббым - Аллаһ», - дисең икән, гел Аның белән генә бул һәм Ул кушканча гына яшә, шулай булса, Ул да гел синең белән булыр һәм ышанучы булып, иман белән дөньядан үтәрсең.

Кайсы китап синең китабың? «Китабым Коръән», - дисеңме? Бик әйбәт. Нәрсә соң ул Коръән? Коръән ул - Аллаһның кешелек дөньясына биргән илаһи программасы һәм инструкциясе. Җир йөзендә кеше кулы белән эшләнгән һәр механизмның да инструкциясе бар. Әгәр инструкциясен үтәмәсәң, ул сафтан чыга. Аллаһ та барча галәмнәрне яралтты һәм кешелек һәлак булмасын өчен яшәү рәвеше ничек булырга тиешлекне Коръәндә ачык бәян итте. «Китабым Коръән», - дисең икән, ул синең тышкы һәм эчке дөньяңның дөрес итеп тәртипкә салуда һәм сиңа Аллаһка якын булуга һәрчак ярдәмче булырга тиеш. Һәр гамәлеңне үзеңне белә башлаганнан алып соңгы сулышыңа кадәр Коръән буенча алып барасың икән, үлемнән курыкма! Ә син Коръәнне кайчан кулыңа аласың? Әллә бер дә алмыйсыңмы? Әллә мәетләр янында, бәйрәмнәрдә, аш мәҗлесләрендә генә укыр өчен кулланасыңмы? Тормышыңны башка кануннарга таянып, башка программалар буенча төзегән булсаң, тынычланма, син Коръән юлында түгел, син нәфес юлында. Син үлгәч, бәлки, сине Коръән укучы, Китап әһеле дип санарлар, әмма синдә Коръәннән һичнәрсә югын белмәсләр. Кайсы китап буенча яшәсәң, шул китап әһеле булып Аллаһ каршында хисап кылынырсың. Бүген кешелек дөньясы хак юлдан тайпылды. Кешеләр бар нәрсәне юктан бар итүче һәм аның Хуҗасы булучыга һәм Аның Китабына җитәрлек игътибар һәм ихтирам белән карамый. Хәтта Аллаһ кушканнарын үтәүне, тыйганнарыннан тыелырга тиешлекне шик астына ала, яралтучының бер колы гына, мәхлугы гына булган кешеләрнең фикеренә өстенлек бирә. Әгәр гел шулай дәвам итсә, кешелекнең киләчәге бик күңелсез бетәр.

Пәйгамбәрең кем? Әгәр: «Пәйгамбәрем Мөхәммәд Мостафа (с.г.в.)», - дип санайсың икән, аның сүзләренә колак сал, ул өйрәткәнчә яшә. Әгәр аның сүзләре синең йөрәгеңдә икән, димәк, син аның өммәте. Пәйгамбәребез өммәтенә мөрәҗәгать итеп: «Мин сезгә ике әйбер калдырам. Әгәр сез шуңа ныгытып ябышсагыз, беркайчан да дөрес юлдан тайпылмассыз. Аның берсе -Аллаһның китабы Коръән һәм минем Сөннәтем», - дигән иде. Хәзер үзеңә сорау бир: Пәйгамбәребезнең Сөннәтеннән синдә нәрсә бар? Иртән торгач тәүге адымыңнан башлап, ашаган ризыгыңның һәр кисәге, йокларга ятуың, балалар тәрбияләвең Пәйгамбәребез өйрәткәнчә булса, димәк, син аның өммәте. Борчылма! Киресенчә икән, тынычланырга иртәрәк. Кемнәр өйрәтүе буенча, кемнәрдән үрнәк алып яшисең, син шулар өммәте. Пәйгамбәребез: «Минем Сөннәтемне ташлаганнар минем өммәтем түгел», - диде. Икенче яшәешне танысаң икән, Ахирәт көненә ышанам, дисең икән, Пәйгамбәребезнең Шәфагатенә ирешерлек итеп бу дөньяда яшәвеңне тәртипкә сал.

Нинди дин - синең динең? Әйе, «дин» дигәндә Ислам дине күз алдына килә. Чөнки барча пәйгамбәрләргә килгән дин – ул Ислам дине. Ислам - кешеләрне Аллаһка якынайта торган бердәнбер юл. Аллаһка якын буласың килә икән, Ислам кануннары буенча яшә. Бу дин - Коръәндә бәян ителгән дин, Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа (с.г.в.) дине, Аллаһ дине. Ә хәзер инде үзеңә сорау бир? Яшәү рәвешеңдә, гаиләңдә Ислам диненнән нәрсә бар, кайсы кануннарын үтисең? Юк икән, димәк, динең Ислам түгел, урының Җәннәттә түгел. Хәтта намаз укыганда да Аллаһны искә алмыйсың икән, димәк, син бу юлда чит кеше, яки икейөзле, ялганчы. Ахирәт газапларыннан котылыйм, дисәң, динең йөрәгең аша үтсен. Әлеге сораулар бик әһәмиятле. Кеше тормышта әллә ниләр эзли, әллә кайларга омтыла, әмма Аллаһтан ерагаеп, чын хакыйкый бәхетне югалтуын күп вакыт үлем килүдән элек аңлый алмый. Шуның өчен Пәйгамбәребез: «Үлем - иң зур гыйбрәт һәм иң зур гыйбадәт», - диде. Үлем безгә ни өчен яшәвебезне аңларга, гамәлләребезне төзәтергә, күңелләребезне нечкәртергә ярдәм итә. Аллаһ барча тереклекне, җир-күкләрне яралтты. Шуларга хәлифә итеп акыл белән зиннәтләп кешене яралтты һәм әйтте: «Ләкаде халәконәәл-иңсәәнә фииии әхьсәни тәкъуиим», - ягъни: «Без Адәм баласын бар нәрсәдән күркәмрәк итеп халик кылдык» («Тин» сүрәсе, 4 нче аять).

Аллаһ биргән акылларыбыз белән фикерләп, бу дөньяда туры юл - дин юлыннан тайпылмыйча, фәкать Аллаһ коллары гына булып, нәфес колы булмыйча яшәргә һәм дөньядан иман белән үтеп, мәңгелек сәгадәткә күченергә Аллаһ һәркайсыбызга насыйп итсен.

Кеше өч нәрсәгә үкәтлеген: байлыкка комсызлыгын, нәрсә дә булса югалтканына кәеф-борчуын, мактанчыклыгын җиңсә, аның иманы ныгый.

**Җәлил хәзрәт ФАЗЛЫЕВ,**
**Татарстанның баш казые.**

## Колак салсаң, үкенмәссең

** Без бөтенебез дә Аллаһы Тәгаләнеке һәм бөтенебез дә Аллаһка кайтабыз*

** Әй Адәм баласы, үлем — ул ишек һәм бар кеше дә ул ишектән керәчәк*

** Әй Адәм баласы, үлем — ул савыт һәм бар кеше дә ул савыттан эчәчәк*

** Әй Адәм баласы! Җиңел йөк - авыр йөккә карый җиңелрәк синең җилкәңә. Ә хисап көнендә, аз мал өчен, күп малга карый җавап бирү дә җиңелрәк*

** Әй Адәм баласы! Син белем ал! Кемнең белеме юк, аның акылы юк, кемнең акылы юк, аның дине дә юк, ә кемнең дине юк, аңа Җәннәт тә юк*

** Әдәпкә күнсәң, адәм булырсың,*
*Яманга күнсәң, әрәм булырсың*

** Йолдыз бик югары да, ул да кое төбенә төшә*

** Берәү бар — Иделдән ил кичергән,*
*Меңнәр бар — ник туганын белми гомер кичергән*

**Әрәм булу җиңел,*
*Адәм булу авыр.*

# Чын бөлгенлек

Без бөлгенлеккә төшүдән уттан курыккандай куркабыз. Гомеребезнең күп өлешен диярлек матди әйберләребезне, малыбызны, акчабызны арттырырга тырышып үткәрәбез. Үзебезгә җиткәндәй булса, балалар, аннан оныклар өчен тырыша башлыйбыз. Аллаһ сакласын, моның өчен алдашырга, урлашырга, сугышырга да мөмкинбез. Дин күзлегеннннән караганда, менә шулар безне чын бөлгенлеккә төшерергә мөмкин дә...

Аллаһ рәсүле (с.г.в.): «Сез беләсезме, кем ул мөфлис (бөлгенлеккә төшүче)?» – дип сорый. «Кемнең дирхәме дә (акчасы да), әйбере дә юк, шул бөлгенлеккә төшүче», – дип җаваплыйлар кешеләр. «Минем өммәтемнең мөфлисе – Кыямәт көнендә намазлары, уразасы, зәкятләре белән килеп басып та, әмма бу дөньяда ул кемгәдер начар сүз әйткән, кемнеңдер гайбәтен сөйләгән, кемнеңдер малын ашаган, кемнеңдер канын агызган, кемгәдер суккан булып чыгып, аның яхшы гамәлләре шул зыян күрүчеләргә таратылып бирелгән, ә инде яхшы гамәлләре барлык күрсәткән зыяннарын капларга җитмәсә, шул җәберсетелгән кешеләрнең гөнаһлы гамәлләре аңа йөкләтелеп, Утка ыргытылган кеше», – ди Пәйгамбәр галәйһиссәләм.

**Дилбәр БУЛАТОВА әзерләде.**

# Кыямәт көненең галәмәтләре

*Кыямәт көненең галәмәтләре*
*(Дәвамы. Башы газетаның алдагы санында)*

Булган һәм кабатланып торган галәмәтләр.

1. Ялган пәйгамбәрләрнең пәйда булуы. Имам Бохариның хәдисләр җыентыгында әйтелә: "Кыямәт көне алдыннан үзләрен пәйгамбәр дип игълан иткән кешеләр утызга якын булыр (икенче хәдистә төгәл 27 дип әйтелә), шулар арасында 4 хатын-кыз була". Әлеге мәсьәлә буенча шунысы мәгълүм: Мусәйләмә исемле кеше Мөхәммәд (с.г.в.) әле исән чакта үзен пәйгамбәр итеп белдертә; Әл-Әсвәд Әл-Ганси дигән кеше Мөхәммәд (с.г.в.) вафат булганнан соң үзен пәйгамбәр итеп игълан итә; Зәҗҗәһә исемле хатын шулай ук үзен пәйгамбәр итеп игълан итә; Кыямәт көне алдыннан булачак иң соңгы ялган пәйгамбәр - Мәсихү-Дәҗҗал.

2. Фетнә, ягъни мөселманнар арасында булган низаглар, сугыш-үтерешләргә илтүче бәрелешләр. Имам Мөслим китабындагы бер хәдистә әйтелә: "Килер шундый вакыт: үтерүче кеше ни өчен үтергәнен белмәс, үтерелгән кеше ни өчен үтерелгәнен белмәс".

3. Дини наданлыкның һәм зина кылу, исерткеч эчү кебек бозыклыкларның артуы һәм киң таралуы, хатын-кызларның күбәюе һәм ирләрнең әзәюе. Пәйгамбәр (с.г.в.) әйтте: "Кыямәт көне алдыннан гыйлем кимер, җәһилият таралыр, зина кылу һәм исерткеч эчү күбәеп китәр, ирләр саны әзәер, хатыннар - артыр, хәтта сан буенча 1 иргә 50 хатын-кыз туры килер".

4. Кеше өстенә төрле афәтләр, бәла-казалар килү (аварияләр, җир тетрәүләр, су басулар, төрле катастрофалар, эпидемияләр, яңа авырулар һ.б.)

**("Ислам дине нигезләре"ннән. Дәвамы бар)**

# Бәхетле бул!

Бөтен байлык, уңыш, сөенеч, бәрәкәт һәм нигъмәтләр кулында булган Аллаһ Тәгаләгә шөкеранабыз һәм иксез-чиксез рәхмәтләребез булсын. Шулай ук бу дөньяда бөтен кешеләргә бәхет һәм сәгадәт теләп, соңгы сулышына кадәр дога кылып яшәгән Мөхәммәд (с.г.в.)нең рухына салаватларыбыз ирешсен.

Хөрмәтле дустым! Аллаһ Тәгалә бөтенебезгә ике дөнья сөенече насыйп итсен. Кемне бәхетлегә санап була һәм бәхет дигән нәрсә бармы дөньяда, дигән сорауга җавап бирү авыр. Чөнки дөньяда яшәгән һәрбер кешенең бәхете үзенчә. Авырып яткан кеше бәхетен шифалануда күрә. Өйләнмәгән яки кияүгә чыкмаган кеше, тормыш иптәшен тапсам бәхетле булырмын, дип фикер йөртә. Фәкыйрь - бәхетне байлыкта күрә һәм мондый үрнәкләрне күп китереп була. Әмма шунысы бик гаҗәп: әлеге мисаллардагы кешеләр, нигәдер, үзләренең максатларына ирешкәннән соң, бәхет эзләүне дәвам итәләр. Бәхет сәламәт булуда, бай булуда, матур һәм дәрәҗәле булуда дип гадирәк итеп әйтсәк, нигә соң ул нәрсәләргә ия булучылар үзләрен бәхетле дип санамыйлар?! Бу авыр сорауга гади һәм иң дөрес җавап шул: "Бәхет күңел тынычлыгында һәм нәфеснең канәгать булуындадыр". Бу җавап белән килешмәгән кешеләр мәгънәсез эзләнүләрен әле дәвам итәчәкләр дип уйлыйм.

Әчке һәм тышкы дөньясы елмаю, шатлык һәм сөенеч белән тулган бер кешедән: "Сез ничек һәрвакыт күтәренке күңел белән яши аласыз? Ни гаҗәп, сезнең йөзегездә елмаю һичбер вакыт сүрелми. Безгә дә шушы хәлгә ирешү юлын өйрәтегез әле. Үзегезнең бәхетле булу серен безгә дә ачсагыз иде", – дип сорыйлар. Бу кеше: "Мин дә нәкъ сезнең кебек бик озак еллар буе күңелсезләнеп, булган һәм булмаган хәлләргә борчылып яшәдем. Әмма бик күп эзләнүләрдән соң шуны аңладым: Аллаһ Тәгалә бу гомерне һәм шуның белән бергә ихтыяр көчен миңа бүләк иткән. Шулай булгач, бәхетле булу яки бәхетсез булу минем кулымда. Һәр көнне иртә белән уянгач, мин үз-үземә: "Бүгенге көнне сөенечтә яки кайгыда уздыру минем үземнән тора. Шуңа күрә бу көннең һәр мизгелен мин сөенечтә, шатлыкта уздырачакмын дип үземә-үзем боерык бирәм", дип сөйләгән иде.

**Мәхмүт хәзрәт ШӘРӘФЕТДИН.**

## ӘДӘБИ СҮЗ

***Рәзинә Мөхияр***

### Ул бит бәхет

*Иртән торып, җиргә*
*бастың,*
*Ул бит бәхет.*
*Кул күтәреп амин тоттың,*
*Ул бит бәхет.*
*Күккә карап хозурландың,*
*Ул бит бәхет.*
*Намазыңны укый алдың,*
*Ул бит бәхет.*
*Кош сайравын син ишеттең,*
*Ул бит бәхет.*
*Аллаһыны зекер иттең,*
*Ул бит бәхет.*
*Җир йөзендә күпме кеше*
*Йөрми, күрми,*
*Ишетәлми, сөйләшәлми,*
*Аллаһыны*
*Зекер итми, амин тотмый,*
*Аллаһының*
*Коръәнен дә укый алмый.*
*Рәхмәт, Раббым,*
*Мин барсын да эшли алам.*
*Бу – бәхетем.*
*Дога кылам бары Сиңа –*
*Җан тәхетем.*

# Мөселман Константин

Евгения малаен сөннәткә утыртты. Диннәрендә андый гадәт юк. Ире күптән чыгып киткән, аңа әйтеп тә тормады. Әтисе белән әнисе картлар, кызларына каршы килмәделәр, "үзең беләсеңдер" дип кенә әйтә алдылар. Күңеле белән киңәшләште дә тәвәккәлләде Евгения.

Ике яшьлек Костя сөннәтле булуын аңламыйча да калды. Үсә төшкәч тә артык кызыксынмады бу хакта, малайлар белән су кергәндә гаҗәпләнеп сорасалар да, җавап бирә алмады; әтисе булмады, әнисеннән сорарга кыенсынды, бабасы үлгән иде инде.

Көн-төн эшләде Евгения. Ике бала – малайларын ашатырга, эчертергә, тәрбияләргә, укытырга – аякка бастырырга кирәк иде. Бигрәк тә төпчеге – Костясы бик шук, күз-колак кирәк. Тормышына зарланмады ул, исәнлеге дә бар, хезмәтен түгеп акчасын таба, хәленнән килгәнчә дөрес яшәргә тырыша, балаларын гел үгет-нәсихәттә тота иде. Ирен генә саклый алмады. Икенче хатынга үз теләге белән чыгып китте. Хәерле булсын!

Үсә төшкәч, Константин әнисенә аз булса да булышыйм дип, ял көннәрендә базарга йөк ташучы булып урнашты. Ни гаҗәп, Костя үзе дә сизмәстән, базар таҗиклары янына тартылды. Алар аны пылау ашарга чакырды. Рәхмәт йөзеннән, малай ашап бетергәч тә битен сыпырып куярга өйрәнде. Өйгә кайтып, әнисенең тәмле ашыннан соң да битен сыпыра торган булып китте. Әнисе малаеның бу гадәтенә сүз әйтмәде.

Малай таҗиклар янында пылау белән сыйлануын дәвам итте. Төшнең бер вакытында, тәмле пылаудан соң, алар каядыр китеп югала иде. Костя башта әллә ни игътибар бирмәсә дә, бервакыт, товар саклый торган бер бүлмәдә, аларның җыелып тезләнеп утырганнарын шәйләде. Ныклабрак караса, йомшак келәмгә тезләнеп утырганнар да, кулларын тез башларына куеп, авыз эчләреннән нәрсәдер укыналар. Озак кына утырганнан соң, маңгайларын идәнгә куялар, уңга-сулга борылып нәрсәдер әйтәләр дә, тегे тәмле пылаудан соң әйтә торган сүзләрен кабатлыйлар. "Аллаһу әкбәр!". Үзе дә сизмәстән Костя бу сүзне аларга ияреп кабатлады. Күңеленә тәмле пылаудан соң була торган халәт иңде. Базардагылар күреп калганчы дип, үз эшендә булды.

Һәр ял көне төштән соң Костяның күңеле шул бүлмәгә тартылды. Тагын бер мәртәбә генә күз салыйм дип килгән җиреннән, аяклары кадакланды, кушылып тезләнәсе, башын иясе килде. Әнә ничек күзләрен йомып, ниндидер рәхәтлек кичерәләр бит алар!

Бер ял көнендә ишек төбендә кыенсынып торганда, артыннан берәүнең, йомшак кына итеп, башыннан сыйпаганын тойды. Борылып караса, карт таҗик, кулы белән ымлап Костяга узарга куша. Сүз катмады карт. Күзләре белән генә ымлады. Костя: "Ярый мени?" – диде. Картның күзләрендә ризалык билгеләре чагыла иде. Костя җыенга соңга калган карт артыннан алдагы сафтагылар янына барып утырды, алар артыннан хәрәкәтләрне кабатлады. Ятты-торды, ятты-торды, бу ятып-торыш мизгел эчендә бетеп тә куйды. Ә күңелендә шул хәрәкәтләрне дәвам итәсе килү теләге калды. "Аллаһу әкбәр"! Соңгы сүзләре Костяга бик таныш иде. Тәмле пылаудан соң да шундый тәм кала бит, ә, дип, авызына килгән төкерекен йотып куйды.

Тән азыгы пылау булса, җан азыгы намаз икәнен Костя аңларлык яшьтә булмаса да, күңеле белән җан азыгы эзли иде.

**Гөлфия НАСЫЙБУЛЛИНА.**

## *ХӘДИСЛӘРДӘ – КҮҢЕЛ ТЫНЫЧЛЫГЫ...*

***Мөхәммәд пәйгамбәр галәйһиссәләм әйтте:***

"Аллаһны исеңдә тот һәм син Аны үз алдыңда күрерсең. Чәчәк аткан вакытыңда Аллаһны бел, Ул сине мохтаҗлыгың вакытыңда белер. Бел: сиңа кагылмый үткән нәрсә сиңа кагылырга тиеш түгел иде. Ә сиңа кагылган нәрсә кагылмыйча үтеп китәргә тиеш түгел иде. Шулай ук бел: түземлектән башка җиңү, югалтудан башка табыш, кыенлыктан башка җиңеллек юк".

***

"Аллаһны исеңдә тот һәм Ул сине яклар. Сорыйсың икән – Аллаһтан сора, ярдәм эзлисең икән – ярдәмне фәкать Аллаһтан өмет ит. Бел: әгәр халык сиңа яхшылык эшләү өчен берләшсә, ул Аллаһ сиңа алдан әзерләп куйган яхшылыкны гына эшли ала. Бел: әгәр халык сиңа яманлык эшләү нияте белән берләшсә, ул Аллаһ сиңа алдан әзерләп куйган яманлыкны гына эшли алачак. Каләм инде аерылган һәм кәгазь битләре инде кипкән".

***

"Мөэминнең һәрбер эше искиткеч гаҗәептер һәм аның һәр эше хәерлегә. Әгәр аңа ниндидер авырлык, кайгы-хәсрәт килсә, ул сабыр итә һәм бу аның өчен хәерледер (бу вакытта мөэмин кеше авырлыкка сабыр иткән өчен һәм бернәрсәгә дә карамастан Раббысына тугрылыклы калган өчен әҗер-савапка ия була). Әгәр Аллаһы Тәгаләдән ниндидер шатлык килсә, иманлы кеше шөкер итә һәм бу аның өчен хәерледер (Раббысына рәхмәтле булганы өчен ул шулай ук әҗер-савап белән бүләкләнә)".

**Ришат хәзрәт КУРАМШИН әзерләде,**
**Кукмара мәдрәсәсе мөдире**

# Намаз вакытлары

| Милади Ноябрь | Көн исеме | Рабигуль-әувәл, рабигуль-ахир | Иртәнге намаз: Таң беленә Уфа | Таң беленә Чаллы | Таң беленә Казан | Мәчетләрдә укыла Уфа | Мәчетләрдә укыла Чаллы | Мәчетләрдә укыла Казан | Кояш чыга Уфа | Кояш чыга Чаллы | Кояш чыга Казан | Зәвәл Уфа | Зәвәл Чаллы | Зәвәл Казан | Өйлә Уфа | Өйлә Чаллы | Өйлә Казан | Икенде Уфа | Икенде Чаллы | Икенде Казан | Ахшам Уфа | Ахшам Чаллы | Ахшам Казан | Ястү Уфа | Ястү Чаллы | Ястү Казан |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Җм | 4 | 04.03 | 04:29 | 04:42 | 04:39 | 05:05 | 05:18 | 06:17 | 06:35 | 06:48 | 13:18 | 11:13 | 11:27 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18:02 | 13:58 | 14:11 | 20:13 | 15:51 | 16:04 | 21:46 | 17:36 | 17:49 |
| 2 | Шм | 5 | 04.06 | 04:31 | 04:44 | 04:41 | 05:07 | 05:20 | 06:19 | 06:37 | 06:50 | 13:17 | 11:13 | 11:27 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 18:00 | 13:56 | 14:09 | 20:10 | 15:49 | 16:02 | 21:44 | 17:34 | 17:47 |
| 3 | Як | 6 | 04.09 | 04:33 | 04:46 | 04:43 | 05:09 | 05:22 | 06:21 | 06:39 | 06:52 | 13:17 | 11:13 | 11:27 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 17:59 | 13:54 | 14:07 | 20:08 | 15:47 | 16:00 | 21:41 | 17:32 | 17:45 |
| 4 | Дш | 7 | 04.12 | 04:34 | 04:48 | 04:45 | 05:11 | 05:24 | 06:23 | 06:41 | 06:54 | 13:17 | 11:13 | 11:27 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 17:57 | 13:53 | 14:05 | 20:05 | 15:45 | 15:58 | 21:39 | 17:30 | 17:43 |
| 5 | Сш | 8 | 04.15 | 04:36 | 04:49 | 04:47 | 05:13 | 05:26 | 06:25 | 06:43 | 06:56 | 13:16 | 11:13 | 11:27 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 17:56 | 13:51 | 14:04 | 20:03 | 15:43 | 15:56 | 21:36 | 17:28 | 17:41 |
| 6 | Чш | 9 | 04.18 | 04:38 | 04:51 | 04:49 | 05:15 | 05:29 | 06:27 | 06:45 | 06:59 | 13:16 | 11:13 | 11:27 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 17:54 | 13:49 | 14:02 | 20:00 | 15:41 | 15:54 | 21:33 | 17:27 | 17:40 |
| 7 | Пҗ | 10 | 04.20 | 04:40 | 04:53 | 04:51 | 05:17 | 05:31 | 06:28 | 06:47 | 07:01 | 13:16 | 11:14 | 11:27 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 17:52 | 13:47 | 14:00 | 19:58 | 15:39 | 15:52 | 21:31 | 17:25 | 17:38 |
| 8 | Җм | 11 | 04.23 | 04:42 | 04:55 | 04:53 | 05:19 | 05:33 | 06:30 | 06:49 | 07:03 | 13:15 | 11:14 | 11:27 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 17:51 | 13:45 | 13:58 | 19:55 | 15:37 | 15:50 | 21:28 | 17:23 | 17:36 |
| 9 | Шм | 12 | 04.26 | 04:43 | 04:56 | 04:55 | 05:22 | 05:35 | 06:32 | 06:52 | 07:05 | 13:15 | 11:14 | 11:27 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 17:49 | 13:43 | 13:56 | 19:53 | 15:35 | 15:48 | 21:25 | 17:22 | 17:35 |
| 10 | Як | 13 | 04.28 | 04:45 | 04:58 | 04:57 | 05:24 | 05:37 | 06:34 | 06:54 | 07:07 | 13:15 | 11:14 | 11:27 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 17:47 | 13:42 | 13:55 | 19:50 | 15:33 | 15:46 | 21:23 | 17:20 | 17:33 |
| 11 | Дш | 14 | 04.31 | 04:47 | 05:00 | 04:59 | 05:26 | 05:39 | 06:36 | 06:56 | 07:09 | 13:14 | 11:14 | 11:27 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 17:46 | 13:40 | 13:53 | 19:48 | 15:31 | 15:44 | 21:20 | 17:19 | 17:32 |
| 12 | Сш | 15 | 04.33 | 04:48 | 05:02 | 05:01 | 05:28 | 05:41 | 06:38 | 06:58 | 07:11 | 13:14 | 11:14 | 11:27 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 17:44 | 13:38 | 13:51 | 19:45 | 15:29 | 15:42 | 21:18 | 17:17 | 17:30 |
| 13 | Чш | 16 | 04.36 | 04:50 | 05:03 | 05:02 | 05:30 | 05:43 | 06:40 | 07:00 | 07:13 | 13:14 | 11:14 | 11:27 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 17:42 | 13:37 | 13:50 | 19:42 | 15:28 | 15:41 | 21:15 | 17:16 | 17:29 |
| 14 | Пҗ | 17 | 04.39 | 04:52 | 05:05 | 05:04 | 05:32 | 05:45 | 06:41 | 07:02 | 07:15 | 13:13 | 11:14 | 11:27 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 17:40 | 13:35 | 13:48 | 19:40 | 15:26 | 15:39 | 21:12 | 17:14 | 17:27 |
| 15 | Җм | 18 | 04.41 | 04:53 | 05:07 | 05:06 | 05:34 | 05:47 | 06:43 | 07:04 | 07:17 | 13:13 | 11:14 | 11:27 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 17:39 | 13:33 | 13:46 | 19:37 | 15:24 | 15:37 | 21:10 | 17:13 | 17:26 |
| 16 | Шм | 19 | 04.43 | 04:55 | 05:08 | 05:08 | 05:36 | 05:49 | 06:45 | 07:06 | 07:19 | 13:12 | 11:15 | 11:28 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 17:37 | 13:32 | 13:45 | 19:35 | 15:23 | 15:35 | 21:07 | 17:12 | 17:25 |
| 17 | Як | 20 | 04.46 | 04:57 | 05:10 | 05:10 | 05:38 | 05:51 | 06:47 | 07:08 | 07:21 | 13:12 | 11:15 | 11:28 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 17:35 | 13:30 | 13:43 | 19:32 | 15:21 | 15:34 | 21:05 | 17:10 | 17:23 |
| 18 | Дш | 21 | 04.48 | 04:58 | 05:12 | 05:12 | 05:40 | 05:53 | 06:49 | 07:10 | 07:23 | 13:12 | 11:15 | 11:28 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 17:33 | 13:29 | 13:42 | 19:30 | 15:19 | 15:32 | 21:02 | 17:09 | 17:22 |
| 19 | Сш | 22 | 04.51 | 05:00 | 05:13 | 05:14 | 05:42 | 05:55 | 06:51 | 07:12 | 07:25 | 13:11 | 11:15 | 11:28 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 17:32 | 13:28 | 13:41 | 19:27 | 15:18 | 15:31 | 20:59 | 17:08 | 17:21 |
| 20 | Чш | 23 | 04.53 | 05:02 | 05:15 | 05:16 | 05:44 | 05:57 | 06:52 | 07:14 | 07:27 | 13:11 | 11:15 | 11:28 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 17:30 | 13:26 | 13:39 | 19:25 | 15:16 | 15:29 | 20:57 | 17:07 | 17:20 |
| 21 | Пҗ | 24 | 04.55 | 05:03 | 05:16 | 05:17 | 05:46 | 05:59 | 06:54 | 07:16 | 07:29 | 13:11 | 11:16 | 11:29 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 17:28 | 13:25 | 13:38 | 19:22 | 15:15 | 15:28 | 20:54 | 17:06 | 17:19 |
| 22 | Җм | 25 | 04.57 | 05:05 | 05:18 | 05:19 | 05:48 | 06:01 | 06:56 | 07:18 | 07:31 | 13:10 | 11:16 | 11:29 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 17:26 | 13:24 | 13:37 | 19:20 | 15:13 | 15:26 | 20:52 | 17:05 | 17:18 |
| 23 | Шм | 26 | 05.00 | 05:06 | 05:19 | 05:21 | 05:50 | 06:03 | 06:58 | 07:20 | 07:33 | 13:10 | 11:16 | 11:29 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 17:24 | 13:23 | 13:35 | 19:17 | 15:12 | 15:25 | 20:49 | 17:04 | 17:17 |
| 24 | Як | 27 | 05.02 | 05:08 | 05:21 | 05:23 | 05:52 | 06:05 | 07:00 | 07:22 | 07:35 | 13:10 | 11:16 | 11:30 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 17:23 | 13:21 | 13:34 | 19:14 | 15:11 | 15:24 | 20:47 | 17:03 | 17:16 |
| 25 | Дш | 28 | 05.04 | 05:09 | 05:22 | 05:25 | 05:54 | 06:07 | 07:02 | 07:24 | 07:37 | 13:09 | 11:17 | 11:30 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 17:21 | 13:20 | 13:33 | 19:12 | 15:09 | 15:22 | 20:44 | 17:02 | 17:15 |
| 26 | Сш | 29 | 05.06 | 05:11 | 05:24 | 05:27 | 05:55 | 06:09 | 07:04 | 07:25 | 07:39 | 13:09 | 11:17 | 11:30 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 17:19 | 13:19 | 13:32 | 19:09 | 15:08 | 15:21 | 20:42 | 17:01 | 17:14 |
| 27 | Чш | 30 | 05.09 | 05:12 | 05:25 | 05:28 | 05:57 | 06:11 | 07:05 | 07:27 | 07:41 | 13:09 | 11:17 | 11:30 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 17:17 | 13:18 | 13:31 | 19:07 | 15:07 | 15:20 | 20:39 | 17:00 | 17:13 |
| 28 | Пҗ | 1 | 05.11 | 05:13 | 05:27 | 05:30 | 05:59 | 06:12 | 07:07 | 07:29 | 07:42 | 13:08 | 11:18 | 11:31 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 17:15 | 13:17 | 13:30 | 19:04 | 15:06 | 15:19 | 20:37 | 17:00 | 17:13 |
| 29 | Җм | 2 | 05.13 | 05:15 | 05:28 | 05:32 | 06:01 | 06:14 | 07:09 | 07:31 | 07:44 | 13:08 | 11:18 | 11:31 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 17:13 | 13:16 | 13:29 | 19:02 | 15:05 | 15:18 | 20:34 | 16:59 | 17:12 |
| 30 | Шм | 3 | 05.15 | 05:16 | 05:29 | 05:34 | 06:02 | 06:16 | 07:11 | 07:32 | 07:46 | 13:08 | 11:18 | 11:31 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 17:12 | 13:15 | 13:28 | 18:59 | 15:04 | 15:17 | 20:32 | 16:58 | 17:11 |

## Саулыгым – байлыгым

# Кишер



Кишер үзе дә, аның суы да бик файдалы. Кишер суы В, С, Д, Е, К витаминнарына бай, анда А витамины (организмга гаять файдалы, аеруча күзләр өчен) күп. Кишер суы аппетитны күтәрә, ашказаны-эчәк системасы эшчәнлеген, тешләр структурасын яхшырта. Йөкле һәм имчәк баласы булган хатыннарга кишер суы эчәргә киңәш ителә. Кишер суындагы матдәләр күзләрнең күрү сәләтен яхшырта, төрле шешләрне (яман шешне дә) дәвалаганда ярдәм итә. Тән тиресе коры булганда, гомумән, тире авыруларын дәвалаганда ул бик файдалы. Эндокрин системасын дәвалый, аны ирләргә женси көчсезлектән, хатыннарга бала тапмаганда кулланырга киңәш ителә. Кишерне көн саен куллану организмны ныгыта, йогышлы авыруларга каршы торучанлыкны арттыра. Аны йөрәк-кан тамырлары, бавыр һәм бөер авырулары булганда азык итеп кулланалар. Шулай ук кишер ашаган кешенең каны, ашказаны чистара, тәнендә ныклык һәм көч арта. Каны аз кешегә дә кишер ашарга киңәш ителә. Әгәр дә җәрәхәтләнгән урынга кишерне төеп япсаң, яра тиз төзәлә, яшь ит үстерә. Тамакта шеш булганда кишер суына яртылаш бал кушып чайкасаң бик файдалы. Кишернең орлыгында да дәвалау үзлекләре бар.

*(Фотолар интернеттан алынды)*

**Нәшире**
**Иршат Гыйльметдин улы ШӘЙХАТТАР**
**Баш мөхәррир**
**Муллагалиева А. Г.**
**Тел.:** (8552) 70-51-09
**Факс:** (8552) 70-51-45

* * *

**Оештыручылары:**
Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан җөмһүрияте мөселманнары Диния нәзарәте, "Ислам нуры" дини эшмәкәрлек Үзәге

Газета мәкаләләрен күчереп басканда аларның "Ислам нуры"ннан алынганын күрсәтү мәҗбүри.

Редакциягә килгән хатларда авторларның стиле саклана.

**Хатларны 423802, Чаллы Үзәк ур., 72 адресы буенча юллау кирәк.**

**Электрон хатлар өчен:**
islamgazeta@mail.ru

Мөселманнар арасын бозуга, үзара каршылыкларга китерергә мөмкин булган хатлар, шикаятьләр газетада басылмый.

Дин-шәригать мәсьәләләренә кагылышлы язмалар, укучы сораулары Татарстан Диния нәзарәтенең баш казые, Чаллы төбәге мөхтәсибәтенең гыйльми Советы тарафыннан өйрәнелә һәм аларга җавап бирелә.

Россия Федерациясе матбугат, телерадиотапшырулар һәм массакүләм коммуникацияләр Министрлыгының Идел буе төбәкара территориаль идарәсендә ПИ № 7-0997 саны белән 2001 елның 15 ноябрендә теркәлде.

"Роспечать" агентлыгы каталогына кертелгән, язылу ел әйләнәсендә Россия Федерациясе буенча алып барыла.

Айга ике мәртәбә чыга.

**Тиражы: 1500**
**Индексы 54149**

* * *

Хөрмәтле укучыбыз!

Газетабызны укып чыккач, аны туганнарыгызга, танышларыгызга, тапшырсагыз иде. "Ислам нуры"ның һәр саны кулдан-кулга күчеп динебезне таратырга ярдәм итсә иде. Әмин.

Шулай ук укучыларыбыз, Коръән аятьләре язылу сәбәпле, газетаны кирәкмәгән урыннарга ташлаудан сакланырлар дип ышанабыз.

* * *

Газета компьютерда җыелды, офсет ысулы белән "Ислам нуры" басмаханәсендә басылды.

**Нәшир, типография һәм редакция адресы:**
**423802, Яр Чаллы, Үзәк урамы, 72**

**Басарга кул куелды:**
**график буенча 10 октябрь 16 сәг.**
**фактта 10 октябрь 16 сәг.**
**Бәясе иркеле**